ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 10 » март 2018 ел № 56

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче система турында

"Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында" 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм "Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында" 2004 елның 10 ноябрендәге 480 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системаның Балтач звеносы турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында нигезләмәне (2 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составын (3 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системаның Балтач звеносының көчләр һәм чаралар составын (4 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы хезмәтләре һәм оешмалары исемлеге һәм аларның Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче система звеносының эшләвен тәэмин итү буенча функцияләрен ( 5 нче кушымта).

2. "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче система

звеносы турында" 2015 елның 27 гыйнварындагы 16 номерлы Балтач муниципаль районы башлыгы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе Р.И. Шакировка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы Р.Р. Нотфуллин